**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасының кайбер торак пунктлары территорияләрендә һәм Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле урнаштырылган карантинны бетерү турында**

Терлекләрнең котыру белән чирләвенең соңгы очрагыннан соң ике ай узуы, эпизоотиягә каршы һәм профилактик чаралар уздырылу белән бәйле рәвештә, «Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-I номерлы Россия Федерациясе Законының $3^1$ статьясы нигезендә **карар бирәм:**

1. Терлекләр котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле кертелгән карантинны бетерергә:

а) Татарстан Республикасының түбәндәге торак пунктлары территорияләрендә:

Биектау районының Каймар авылы;

Биектау районының Туктамыш авылы;

Биектау районының Юртыш поселогы;

Питрәч районының Иксуар авылы;

Тукай районының Артамоновка авылы;

б) Татарстан Республикасының түбәндәге аерым территорияләрендә:

Балтач районының Түбән Субаш авылындагы Нагорный урамы;

Биектау районының «Туган Як» коммерциячел булмаган бакчачылык ширкәте;

Кама Тамагы районының Олы Салтык авылындагы Яңа урам;

Лаеш районының 25 Октябрь исемендәге совхоз поселогындагы Октябрь урамы;

Балык Бистәсе районының Ямаш авылындагы Яшьләр урамы;

Саба районының Олы Кибәче авылындагы Гагарин урамы;

Саба районы Яулаштау авылы янындагы «Саба» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең яшь терлек асрау өчен файдаланылучы территориясе;

Саба районының Юлбат авылындагы Күл урамы.

2. Үз көчләрен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының кайбер торак пунктлары территорияләрендә һәм Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә терлекләр котыру авырулы

булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертү турында» 2014 елның 22 сентябрендәге ПУ-914 номерлы Указы;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертү турында» 2014 елның 9 декабрендәге ПУ-1121 номерлы Указы;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының кайбер торак пунктлары территорияләрендә һәм Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертү турында» 2014 елның 22 сентябрендәге ПУ-914 номерлы Указы;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Биектау районының Туктамыш авылы территориясендә терлекләр котыру авырулы булганга, аның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертү турында» 2014 елның 10 декабрендәге ПУ-1122 номерлы Указы.

3. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан,Кремль
2015 ел, 14 февраль
№ ПУ-120